ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**05.08.2017**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2126**

Гражданнарның янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүдә, шул исәптән Зеленодольск муниципаль районы территориясендә ирекле янгын күзәтчелеге эшчәнлегендә катнашу формаларын билгеләү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 14 статьясындагы 1 пунктының 9 пунктчасын, "Янгын куркынычсызлыгы турында" 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясын, булган матди кыйммәтләрне максималь саклап калу, гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген мөмкин булган янгыннардан саклау максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Гражданнарның янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүдә, шул исәптән Зеленодольск муниципаль районы территориясендә ирекле янгын күзәтчелеге эшчәнлегендә катнашу формаларын билгеләү турындагы нигезләмәне, кушымта нигезендә, расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы А.В.Старостин

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 05августының 2126 номерлы карарына
кушымта

**Гражданнарның янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүдә, шул исәптән Зеленодольск муниципаль районы территориясендә ирекле янгын күзәтчелеге эшчәнлегендә катнашу формаларын билгеләү турында нигезләмә**

Нигезләмә «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә эшләнде.

Төп төшенчәләр

Янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары-янгын сүндерүне оештыру чаралары комплексының бер өлеше булып торган, янгыннарны булдырмау , кешеләрне һәм мөлкәтне янгыннан коткару буенча билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән нормаларны һәм кагыйдәләрне гамәлгә ашыру.

Янгынга каршы пропаганда – халыкка яшәү урыны, эш урыны буенча гражданнар җыелышларында гамәлгә ашырыла торган янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү проблемалары һәм юллары турында максатчан мәгълүмат бирү, тематик күргәзмәләр, смотрлар, конференцияләр уздыру һәм халыкка мәгълүмат бирүнең законнар белән тыелмаган башка формаларыннан файдалану.

Янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары

Янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) авыл җирлегенең янгын куркынычсызлыгын оештыру-хокукый, финанс, матди-техник тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;

2) территорияне үстерү планнарында һәм программаларында каралырга тиешле авыл җирлегенең һәм муниципаль милек объектларының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганакларының тиешенчә торышын тәэмин итү, муниципаль милектәге торак һәм иҗтимагый биналарның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын төзек хәлдә тоту;

3) янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре буенча муниципаль максатчан программалар әзерләүне һәм үтәүне оештыруны;

4) авыл җирлеге территориясендә янгын сүндерү һәм авария-коткару эшләрен башкару өчен көчләр һәм чаралар җәлеп итү планын эшләү һәм аның үтәлешен контрольдә тоту;

5) авыл җирлеге территориясендә махсус янгынга каршы режим, шулай ук ул эшләгән вакытта янгын куркынычсызлыгы буенча өстәмә таләпләр билгеләү;

6) янгын сүндерү техникасының янгын урынына каршылыксыз узуын тәэмин итү;

7) янгын турында халыкка элемтә һәм хәбәр итүне тәэмин итү;

8) халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүне һәм янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә пропаганда оештыру, янгын-техник белемнәрне таратуга ярдәм итү;

9) гражданнарның һәм оешмаларның ирекле янгын күзәтчелегендә катнашуын, шул исәптән янгынга каршы көрәштә катнашуын социаль һәм икътисади стимуллаштыру.

Янгынга каршы пропаганданы гамәлгә ашыру һәм халыкны янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларына өйрәтү тәртибе

Янгынга каршы пропаганда һәм халыкны яшәү урыны буенча янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларына өйрәтү түбәндәгеләр аша гамәлгә ашырыла:

- тематик күргәзмәләр,
- матбугат чаралары, белешмәләр ;
- гражданнар җыелышларында телдән агитация, докладлар, лекцияләр, әңгәмәләр;
- күрсәтмә агитация чаралары (плакатлар, иллюстрацияләр, буклетлар);
- янгынга каршы белемнәрне пропагандалау буенча оешмалар белән эшләү.

Мәктәпкәчә мәгариф учреждениеләрендә һәм гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучы затларга башлангыч янгын куркынычсызлыгы чараларында белем бирү гамәлдәге законнар, Россия Федерациясендә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре нигезендә расланган махсус программалар буенча үткәрелә һәм түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

- гомуми белем бирү учреждениеләрендә «Тормыш эшчәнлеге иминлеге нигезләре» предметын укыту;
- төрле яшьтәге балалар арасында тематик иҗади конкурслар үткәрү;
- гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары арасында янгын сүндерү-гамәли спорт чараларын үткәрү;
- янгын-коткару подразделениеләрендә экскурсияләр күрсәтеп үткәрү һәм тормыш иминлеге нигезләре буенча ачык дәрес үткәрү;
- тематик викториналар оештыру;
-җәйге сәламәтләндерү лагерьларында янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү эшен оештыру;
- янгын куркынычсызлыгы почмакларын рәсмиләштерү.

Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә органнары вәкаләтләре

- ирекле янгын күзәтчелеген оештыру өчен, шулай ук гражданнарның янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын башка формаларда тәэмин итүдә катнашуы өчен шартлар тудыру;

- янгын сүндерү максатларында, елның теләсә кайсы вакытында авыл торак пунктларында һәм аларга якын территорияләрдә урнашкан тышкы су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу өчен шартлар тудыру;

- гомуми файдаланудагы территорияләрне беренчел янгын сүндерү чаралары һәм янгынга каршы инвентарь белән җиһазландыру;

- янгын турында Дәүләт янгынга каршы тору хезмәтене бүлекчәләренә һәм халыкка хәбәр итү чараларын оештыру һәм кабул итү;

- Дәүләт янгынга каршы тору хезмәте бүлекчәләре килеп җиткәнче янгынны локальләштерү, кешеләрне һәм мөлкәтне коткару буенча чаралар күрү;

- җирлекләр территорияләрен үстерү планнарына, схемаларына һәм программаларына янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын кертү;

- Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына халыкка янгын куркынычсызлыгы чаралары турында, шул исәптән халык җыелышларын оештыру һәм уздыру юлы белән хәбәр итүдә ярдәм күрсәтү;

- янгын куркынычы арткан очракта махсус янгынга каршы режим билгеләү.

Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә гражданнарның хокуклары һәм бурычлары

Гражданнар түбәндәгеләргә хокуклы:

- янгын чыккан очракта үзләренең тормышын, сәламәтлеген һәм мөлкәтен сакларга;

- гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә янгын китергән зыянны капларга; үзләренең сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә зыян салган янгын сәбәпләрен билгеләүдә катнашырга;

- янгын куркынычсызлыгы мәсьәләләре буенча мәгълүмат алу, шул исәптән янгын куркынычсызлыгы идарәләре һәм бүлекчәләреннән билгеләнгән тәртиптә.

Гражданнарның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдә катнашу формалары

а) эштә һәм көнкүрештә:

- эштә һәм көнкүрештә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү;

- үзләрендә булган биналарда һәм корылмаларда, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренә ярашлы рәвештә, янгын сүндерүнең беренчел чаралары һәм янгынга каршы инвентарь булдыру;

- янгыннарны ачыклаганда алар турында кичекмәстән янгын сагына хәбәр итәргә;

-янгын сүндерүчеләр килгәнче, кешеләрне, мөлкәтне коткару һәм янгын сүндерү буенча мөмкин кадәр чаралар күрергә;

- янгыннарны сүндергәндә янгын сагына ярдәм итәргә;

- дәүләт янгын күзәтчелеге вазыйфаи затларының күрсәтмәләрен, карарларын һәм башка законлы таләпләрен үтәргә;

- Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә дәүләт янгын күзәтчелеге вазыйфаи затларына янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешен контрольдә тоту һәм аларны бозуларны туктату максатларында,

үзләренә караган җитештерү, хуҗалык, торак һәм башка биналарны һәм корылмаларны карап чыгарга һәм тикшерү үткәрү мөмкинлеге бирергә.

б) ирекле янгын сагында:

- үзләренең эшлекле һәм әхлакый сыйфатлары, шулай ук сәламәтлекләре буенча янгыннарны кисәтү һәм (яки) сүндерү белән бәйле бурычларны үтәргә яраклы гражданнарга ирекле янгын сүндерүче булып индивидуаль тәртиптә ирекле нигездә керү;

- авыл җирлегенең тиешле территориясендә (оешмада) янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү эшчәнлегендә катнашу;

-мәктәпкәчә һәм мәктәп яшендәге балаларны, мәгариф учреждениеләре укучыларын, эшкә сәләтле халыкны һәм пенсионерларны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүдә, шулай ук аларның янгын чыкканда эш итүгә әзерлеген гамәлгә ашыруда катнашу;

- янгынга каршы пропаганда уздыруда катнашу;

- ирекле янгын сагы бүлекчәләрендә хезмәт итүдә(дежур торуда) катнашу ;

- янгыннарны кисәтүдә катнашу;

- янгыннарны сүндерүдә катнашу;

- Зеленодольск муниципаль районының тиешле территориясендә объектларның яки аларның аерым участокларының янгынга каршы торышын тикшерү.

Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге оешмаларның хокуклары, бурычлары

Оешма җитәкчеләре түбәндәгеләргә хокуклы:

- үз акчалары хисабына тоткан янгын күзәтчелеге бүлекчәләрен билгеләнгән тәртиптә булдырырга, үзгәртеп корырга һәм бетерергә;

- дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча тәкъдимнәр кертергә;

- предприятиеләрдә булган янгыннарның сәбәпләрен һәм шартларын билгеләү буенча эшләр алып барырга; янгын куркынычсызлыгы сораулары буенча, шул исәптән идарә органнарыннан һәм янгын күзәтчелеге бүлекчәләреннән мәгълүмат алырга.

Оешмалар җитәкчеләре түбәндәгеләргә бурычлы:

- янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәргә, шулай ук янгын күзәтчелеге вазифаи затларының күрсәтмәләрен, карарларын үтәргә;

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын эшләргә һәм гамәлгә ашырырга;

- янгынга каршы пропаганда үткәрергә, шулай ук үз хезмәткәрләрен янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтергә;

- системаны һәм янгынга каршы саклану чараларын, шул исәптән беренчел янгын сүндерү чараларын төзек хәлдә тотарга, аларны максатсыз куллануга юл куймаска;

- янгын сүндергәндә, аларның барлыкка килү һәм булу сәбәпләрен һәм шартларын билгеләгәндә, шулай ук янгын куркынычсызлыгы таләпләрен

бозуда һәм янгыннар килеп чыгуда гаепле кешеләрне ачыклаганда янгын сагына ярдәм күрсәтергә;

- янгын күзәтчелеге вазифаи затларына территориядә, биналарда, корылмаларда һәм предприятиенең башка объектларында үз хезмәт бурычларын үтәгәндә керү мөмкинлеген тәэмин итәргә;

- дәүләт янгын күзәтчелеге вазыйфаи затлары таләбе буенча предприятиеләрдә янгын куркынычсызлыгы торышы турында, шулай ук үзләренең территорияләрендә булган хәлләр, янгыннар һәм нәтиҗәләр турында белешмәләр һәм документлар бирергә;

- янгын сагына барлыкка килгән янгыннар, булган системаларның һәм янгынга каршы саклану чараларының төзексезлеге, юлларның һәм тыкрыкларның торышы үзгәрүе турында хәбәр итәргә;

ирекле янгын сүндерү дружиналары эшчәнлегенә булышу.

Оешма җитәкчеләре ведомство карамагындагы объектларда үз компетентлыклары чикләрендә янгын куркынычсызлыгы системасы белән турыдан-туры җитәкчелек итәләр һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү өчен шәхси җаваплылык тоталар.

Ирекле янгын сагы

Ирекле янгын саклау - гражданнарның беренчел янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүдә катнашу формасы.

Ирекле янгын сүндерүче - янгынны кисәтү һәм сүндерү янгынны буенча янгын сагы бүлекчәләре эшчәнлегендә ирекле нигездә (хезмәт килешүе төземичә) турыдан-туры катнашучы граждан. Ирекле янгын сагында катнашу авыл җирлеге администрациясе тарафыннан билгеләнгән социаль әһәмиятле эшләрнең бер төре булып тора.

Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын финанс белән тәэмин итү

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын финанс белән тәэмин итү авыл җирлегенең чыгым йөкләмәсе булып тора һәм әлеге максатларга җирлек бюджетында каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла.